*/Мәктәп тормышы/*



## *Мәктәптә – кошлар көне*

Кошлар – табигатьнең күрке. Алардан башка тирә-ягыбыз җансыз булыр иде. Кошлар бик күп зарарлы бөҗәкләрне юк итәләр, сайраулары белән тормышыбызга ямь өстиләр. Әйе, яз җиту белән кошлар кайта, куктә, агач башларында яңадан тормыш башлана. Гаҗәеп матур күренеш бит ул кошларның туган якларына әйләнеп кайтуы. Шул ук вакытта кошлар безнең ярдәмгә дә мохтаҗ.

1 апрель – Халыкара кошлар көне уңаеннан без дә мәктәбебездә башлангыч сыйныф укучылары арасында "Канатлы дусларыбыз" дип аталган чара үткәрдек. Чара КВН формасында үтте. "Сандугачлар" һәм "Тукраннар"командалары көч сынаштылар. Чара барышында балалар кошлар турында күбрәк белер өчен төрле биремнәрдә катнаштылар, табышмаклар чиштеләр, әкият һәм хикәя геройлары булган кошларны таныдылар.



Кошлар бәйрәме алдыннан балаларга өй эше бирелгән иде. Әтиләре белән берлектә кошларга оя ясарга һәм шул ояларны тотып фотога төшәргә кушылды. Бу эштә бик актив катнашкан укучыларыбызны санап үтәсем килә. I нче сыйныфтан Хәйруллин Мансур, III нче сыйныфтан Камалов Илнур, Закиров Инсаф,Залиев Илфир, Сафиуллина Гөлсем, IVнче сыйныфтан Хусенов Дима, Мифтахов Рамазан. Алар бик матур оялар ясаганнар һәм фотоларга төшеп безгә җибәрделәр.

Бәйрәм барышында балаларга канатлы дусларыбыз турында бик күп мәгълумат җиткерелде. Укучыларыбыз кошларның дуслары булырга, аларга ярдәм итәргә,сакларга кирәклегенә төшенделәр.

***Сирин Камалова, башлангыч сыйныфлар укытучысы***

*/Күңелле тәнәфес/*

## *ВИКТОРИНА*

1. 1895нче елда туган татар шагыйре.
2. Тукайның туган авылы.
3. Татар телендә кеше исемнәре сүзлегенең авторы.
4. 2024 нче елда Тукай бүләгенә лаек булган язучы.
5. XIX йөздә университетта рус теле укыткан татар кешесе.
6. Казанда Тукай яшәгән кунакханәнең исеме?
8. Болгар дәүләтендәге шәһәр.
9. Казан губернасында туган рус шагыйре.
10. Сөембикәнең улының исеме.
11. 1843 елда Казан университетында эшләгән каллиграф.
12. 1755 нче елда татар-башкорт явының рухти җитәкчесе Батыршаның исеме.
13. Татар телендә медицина фәненең әлеккеге атамасы.
14. Татарның беренче дирижеры.
15. Ф.Әмирхан чыгарган газета.
16. Татарча беренче операның авторы, исеме?
17. Тукай язышкан сатирик журнал.
18. XX гасыр башында Франциядә укыткан татар галиме

*/Безнең спорт/*




Норлат шәһәренең «Тулпар» спорт сараенда Татарстан буенча билбау көрәшендә җиңүчеләрне бүләкләү булып узды. Биредә ике көн дәвамында Социалистик Хезмәт Герое Габбас Гыйматдинов истәлегенә республика беренчелеге үткәрелде. Җиңүче һәм призер исеме өчен Татарстан Республикасының 18 районыннан 2010-2012 елгы 220 егет һәм кыз көрәште. Җиңүчеләр арасында мәктәбебезнең V сыйныф укучысы **Җамалетдинов Зөлфәт** III урынга лаек булды. Зөлфәткә һәм аның иптәшләренә алдагы бәйгеләрдә зур уңышлар теләп калабыз.

*/Котлыйбыз!/*



Апрель аенда дөньяга килгән рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Кадыйрова Гөлнур апаны**, биология-химия укытучысы **Туктамышев Рифкать абыйны**, мәктәпнең завучы **Сафиуллин Илдар абыйны** туган көннәре белән тәбрикләп, аларга ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, мактаулы хезмәтләрендә зур уңышларга ирешүләрен теләп калабыз.

Бу айда туган укучылардан IV сыйныфтан **Хафизов Ирекне**, VIIсыйныфтан **Залиева Василәне** котлыйбыз. Аларга сәламәтлек, тырышлык, әти-әниләренең горурлыгы булып үсүләрен телибез.

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары: Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин



# Мәктәп хәбәрчесе

**№4**
**(№55)**
**апрель 2024 ел**

Түбән Майна урта мәктәбе газете

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru






*/Мөгаллим киңәше/*

## *Туган телебезне саклау – заман таләбе*

***"Туган телеңне онытсаң, рухыңны югалтырсың…"***

***Габдулла Тукай***

26 нчы апрель көнне бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулды! Габдулла Тукай – татарларны бөтен дөньяга таныткан шагыйрь. Ул дөньяда нибары 27 ел гына яшәгән, бары тик 8 ел иҗат иткән – шулай да безгә бәяләп бетермәслек әдәби мирас бүләк итеп калдырган. Аның кыска гына иҗат юлы дәвамында язып калдырган шигырьләре бүгенге көндә дә бик актуаль.

Тукай үзенең иҗаты аша укучыны табигатьне яратырга, тырыш булырга, күп белемгә омтылырга өнди. Ә иң мөһиме- ул туган телне яратырга, аны сакларга, шуның белән буыннар бәйләнешен сакларга чакыра. Юкка гына Тукай туган көн - Туган тел көне буларак та билгеләнеп узмый. Бөек шагыйребезнең "Туган тел" шигыре генә дә татар халкы өчен юл күрсәтүче һәм горурланып башкарыла торган гимн булып тора.



"...И туган тел, и матур тел әткәм-әнкәмнең теле!

Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы..."

Безнең туган телебез– татар теле. Зур тарихлы, иң бай һәм камил телләрнең берсе. Шушы телдә 7 миллион халык сөйләшә, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, утларга-суларга салсалар да, чукындырсалар да, ассалар-киссәләр дә исән калган, иң-иң авыр кимсетүләр-гә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле!

Ләкин бүгенге көндә без Тукай язып калдырган васыятьләрне үтибезме соң? Телебезне саклыйбызмы? Балаларыбызга өйрәтәбезме? Кызганыч, ләкин тормышта телебезне куллану көннән көн кими бара, үзебезнең телдә булган сүзләрне онытып аларны рус теленнән кергән сүзләр белән алыштырабыз, үзебез дә сизмәстән телебезне пычратабыз, ярлыландырабыз. Ана телебезгә игътибарсыз, ваемсыз караш, күңелне рәнҗетә торган фактлар аеруча соңгы елларда көчәйде.

Бөек галимебез Садри Максуди "Телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап без бетә башлаячакбыз" – дигән. Туган телне белмәү проблемасы, балаларның татар телен аңламаулары күпләребезне борчый.Үзебезнең мәктәп елларын искә төшерсәк, безгә рус теле дәресендә аңламаган сүзләребезне укытучы апалар татар теленә тәрҗемә итәләр иде. Ә хәзер исә, татар теле дәресләрендә балалар рус теленә тәрҗемә сорыйлар, үзара да күбрәк рус телендә аралашалар. Бу бик күңелсез күренеш. Ата-бабаларыбызның дан һәм намус варислары булган балаларда туган телгә кимсенеп карауны тиз көннәрдә бетерәсе иде. Моның өчен мәктәп тә күп көч куя. Туган телебездә театр түгәрәге эшләп килә, сыйныфтан тыш чаралар, бәйрәмнәр даими үткәрелеп бара. Тел дәресләрендә туган телгә карата фикер алышулар да үткәрелә.

Әмма, шуны әйтәсе килә – ана телен өйрәнү гаиләдән башланырга тиеш. Юкка гына да бит ул "АНА ТЕЛЕ" дип аталмаган. Сабыйга иң якын кеше ул - әни. Ул анардан беренче сүзен ишетә, теле дә баланың "әннә" дип ачыла. "Бала чакта алган туган телен һәм инде тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас", – дип юкка гына әйтмәгән бөек мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин. Гаиләләребездә балаларыбыз белән татар телендә генә сөйләшсәк иде.Татарча журналларга язылыйк, бергәләп үз телебездә китап укыйк, татарча җырлар тыңларга өйрәтик балаларны.

Шушы максатлардан чыгып, Тукай туган көнендә аның шигырьләрен ятлап, әкиятләрен сәхнәләштереп, кечкенә генә бәйрәм ясадык. Эшнең башлануы авыр булса да, ятлатыр өчен күп көч куйсак та, кичәнең ахыры күңелле булды. Чөнки укучылар үзләре дә канәгать булдылар. Беренчедән, күпме мәгълүмат; икенчедән, сәхнә ялау; өченчедән, аралашу. Ә аралашу – кеше өчен иң кыйммәтле чара. Укучыларыбызга шушы аралашуның туган телдә булырга тиешлеген дә аңлата алган булсак, бәйрәмнең максаты үтәлгән булыр. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү –һәр кешенең изге бурычы булып тора.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныфлар укытучысы***



**/Безнең бәйрәмнәр/**

## Ураза гаетен каршыладык

Рамазан ае тәмамлану уңаеннан билгеләп үтелүче зур бәйрәм –Ураза гаете. Бу көнне иртән мәчетләрдә гает намазы укыла. Бәйрәм намазыннан соң мөселманнар бер-берсен тәбрик итәләр. Һәр йортта бәйрәм өстәле, коймак, таба ашы әзерләнә. Бәйрәм өч көн дәвам итә. Туганнар, дуслар белән күрешү, авыру кешеләрнең, ялгызларның, өлкәннәрнең хәлен белешү, зиратларга бару, мәрхүмнәрне догалар белән искә алу – бәйрәмнең матур гадәтләре.

Быел да без Ураза гаетен, гадәттәгечә, зурлап үткәрдек. Гает көнне мәчеттә балалар өчен бәйрәм оештырылды. Укучылар кызлар һәм малайлар төркемнәренә бүленеп ярыштылар. Бәйрәм чарасы азан әйтү белән башланып китте. Балалар мөнәҗәтләр әйттеләр. Коръәннән сүрәләр укыдылар, кызлар Ибраһим пәйгамбәрнең (г.с.) тормышын сәхнәләштерделәр. Ә малайлар Аллаһ Тәгаләнең барлыгын һәм берлеген аңлата торган, Аның барлык тереклекне барлыкка китерүче булуын күрсәтә торган өзек күрсәттеләр.

Бәйрәмгә Чистай районыннан кунаклар да килгән иде. Бәйрәм ахырында аларга да сүз бирелде. Күп еллар дәвамында дин укыткан мөгаллимә апалар безнең укучыларга һәм укытучыларга мактау һәм рәхмәт сүзләрен җиткерделәр, балаларга тәмле күчтәнәчләр бирделәр.

Балалар мәчеттә ярышкан арада урамда Әнвәр абый пылау пешерде. Укытучы абыйлар самовар кайнаттылар. Ашханәдә эшләүче апалар тәмле коймак пешереп килде. Башка авылдашлар да бәйрәмгә килгәндә өстәлгә куяр өчен тәмле ризыклар алып килделәр. Өстәлләребез төрле сыйлардан сыгылып торырлык иде. Бәйрәм тамашасыннан соң барлык килгән кунаклар, катнашучы балалар тәмле пылаудан авыз итеп, бәйрәм коймагы белән чәй эчеп, бүләкләр алып таралыштылар. Ә күп бүләкләрне Рамазан аенда мәчеткә тәрәвих намазына йөрүче малайлар һәм кызлар ала. Мондый балалар мәчеттә ел саен арта бара. Менә шул рәвешчә бездә гает бәйрәмнәре бик күңелле һәм күркәм булып уза.

Бәйрәмне оештырган укытучы апаларга, Гөлүсә апага рәхмәт. Безне ел саен күп бүләкләр белән шатландырганы өчен Рафик абыебызга зур рәхмәт әйтәбез.

***Гөлсем Сафиуллина, IIIсыйныф укучысы***

---



**/Туган ягым – яшел бишек/**

## Авылыбыз урамнары – безнең йөзебез

Яз – табигатьнең кышкы йокыдан уяну вакыты. Без аның килүен көтеп алсак та, яз җиту белән кыш буе кар астында күренми яткан чүп-чар баш калкыта башлый. Кыштан соң табигать уяна, тирә-якны тәртипкә китерү, төзекләндерү вакыты җитә.

Яз өмәләре табигатьнең яшәргән, ямьләнгән, яшеллеккә күмелгән чагына туры килә. Мәктәп тирәсен, елга буйларын чистарту эшләрен башкару– алдыбызда торган бер мөһим бурыч. Гомумән, чисталык мәсьәләсе һәрдаим игътибар үзәгендә булырга тиеш. Без дә мәктәп укучылары белән 22 апрель иртәсендә өмәгә дип җыелдык. Бу көнне барлык укучылар, укытучылар, хезмәткәрләр бердәм булып мәктәп тирәсен, балалар уйный торган мәйданчыкларны, һәйкәл янын тырмалап, себереп, чүпләрне җыештырып бик зур эш башкардылар. Ә инде 28 апрель иртәсендә Чирмешән елгасы тирәсен чистарту, язгы ташу алып килгән чүпләрдән арындару өчен тагын бер өмә узды. “Язгы игелек атналыгы" акциясе кысаларында, мәктәп укучылары һәм укытучылары 94 яшьлек тыл ветераны – Фаизә апаның турыларын да җыештырдылар. Һәр килгән кеше хәленнән килгәнчә бу мөһим чарада да актив катнашты. Апа-абыйлар янында балаларның да булуы тагын да сөенөрә. Олыларың үрнәгендә балалар эшкә өйрәнәләр, буыннар арасында да бәйләнешләр ныгый.

Яшәгән тирәбезне җыештыру җиңел эш түгел. Ләкин матурлыкны күрә белү, шул чисталыкны саклап тору тагын да катлаулырак. Гаиләләрдә, мәктәптә бу мәсьәләгә кубрәк игътибар ителсә иде. Яшәгән җиребезне чиста тоту – һәркемнең изге бурычы. Әйләнә-тирәбездәге чисталык һәм матурлыкны булдыру һәм саклау бары тик үзебезнең кулларда икәнен онытмыйк, дуслар!

***Зәйнәп Нурматова, Хсыйныф укучысы***



**/Мәктәп тормышы/**

## Апрельдәге истәлекле көннәр

2 апрельдә безнең мәктәптә тәрбия буенча директор киңәшчесе Динә апа 7-11 сыйныфларга "Без терроризмга каршы" дигән сыйныф сәгате үткәрде.Чараның төп максаты – балаларга терроризм төшенчәсен аңлату, уяулык күрсәтү зарурлыгын аңлату, теракт шартларында үз-үзеңне тотуның төп кагыйдәләре белән таныштыру.

---

12 апрель – Космонавтика көне, кешелек тарихының истәлекле датасы. Бу көнне беренче кеше – Юрий Гагарин космоска очты. Шушы уңайдан кече яшьтәге балалар белән галәм турында белемнәрне үзләштерү, оригами ысулы белән уенчык ясарга өйрәтү булды. Балалар бик кызыксынып очучыларның тормышы, киемнәре, аларның ачык космоска чыгулары турында тыңладылар. Мәктәп укучыларына да бу дата турында сыйныф сәгатьләре уздырылды.



Шулай ук өлкән сыйныфларда да «Космик Россия: космик тармактагы һөнәрләр һәм казанышлар турында беләм»темасы каралды. Дәрестә укучылар космос серләре пәрдәсен ачтылар һәм космик киңлекне үзләштерүдә никадәр ерак адым ясаганыбызны күрделәр, космик тармакның илебез өчен әһәмияте һәм аның хәзерге үсеше турында фикер алыштылар. Дәрес барышында «Было-стало»уены уйналды. Ә видеоны карагач, космос тармагының үткәне һәм бүгенгесе турында белдек. Дәрес тәмамлангач, йөз ел эчендә кешелек меңнәрчә еллар дәвамында кешеләр уйламаганны һәм тагын күпме эшләргә кирәклеген эшләгән дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Ай һәм Марсны үзләштерү, яңа планеталар һәм галактикалар ачу безнең тормышыбызда реаль булырга мөмкин.

---



18 нче апрельдә укучыларга сыйныфтан тыш эшчәнлекнең "Сәнәгатьтәге һөнәрләр" дигән дәрес карадык. Илебездә инженерларның эшчәнлеге, нинди өлкәдә хезмәт куюлары турында белдек. Әлбәттә,инженер һөнәрен үзләштерү өчен нинди фәннәрне ныклап өйрәнергә икәнен дә белдек.

---

2021 елның 19 апреленнән алып Бөек Ватан сугышы елларында нацистлар һәм аларның ярдәмчеләре тарафыннан совет халкының геноциды истәлегенә бердәм гамәлләр көне уздырыла.Безнең мәктәптә бу көн хөрмәтенә укучылар советы, тәрбия буенча киңәшче белән берлектә тарихи хәтерне саклауга юнәлтелгән стенд төзеделәр. Анда хәтер көне, төп даталар, проектлар һәм акцияләр чагылдырылды.

---



Мәктәптә психология атналыгы 22 нче апрельдән башланып бер атна дәвам итте. Аларда укучылар, педагоглар катнашты. Психология атналыгы кысаларында сыйныф сәгатьләре, «мәктәп тормышы Лайфхаклары» дигән иҗади плакатлар күргәзмәсе, «шатлык һәм теләкләр” стенды ясалды. Барлык чаралар да, үз-үзеңне танып белүгә, уңай эмоцияләр формалаштыруга, ассоциатив фикерләү һәм хыялны үстерүгә, балаларның һәм өлкәннәрнең бер-берсенә толерант мөнәсәбәтен активлаштыруга юнәлдерелгән иде.

---



27 нчы апрельдә Россия парламентаризм көне билгеләп үтелә.Безнең мәктәптә бу көн хөрмәтенә VII сыйныф укучылары арасында дебатлар үтте. Әлеге чарада "Мәктәп формасы кирәкме, юкмы?" – дигән проблема күтәрелде.Дебатларда катнашучы укучылар куелган мәсьәләгә карата үз фикерләрен белдерергә, дәлилләр китерергә тырыштылар. Дебатларны алып баручы Динә апа интернеттан файдалану мөмкинлеген бирсә дә, укучылар бу чыганакка мөрәҗәгать итмәделәр.

***Ләйсән Закирова, VI сыйныф укучысы***